ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.03.2023 Баулы шәһәре №62

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 118 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 118 номерлы карарына (2022 елның 4 апрелендәге № 61 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

1 нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

1.5. пункттагы 3) һәм 4.1.) пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) аларның билгеләнешен билгеләү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган ярдәмче корылмалар төзү,

4.1.) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;

түбәндәге эчтәлекле 1.6. пункт өстәргә:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү каралмаган.»;

2 нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.6.1. пунктына түбәндәге эчтәлекле 8) пунктча өстәргә:

«8) капиталь төзелеш объектының архитектур күренешен мондый килештерү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган очракта килештерү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров